**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 июнендәге 1704 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Мәскәү районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2, 3 һәм 4 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- ЗУ 1 йогынты ясый торган өлкә мәйданы – 3669 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:310604:78, 16:50:310604:292, 16:50:310604:77, 16:50:310604:52, 16:50:310604:51, 16:50:310604:3, 16:50:310604:293, 16:50:310604:294, 16:00:000000:68393;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталлары – 16:50:310604, 16:00:000000, 16:50:000000;
- ЗУ 2 йогынты ясый торган өлкә мәйданы – 1440 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:310604:3, 16:50:310603:401, 16:50:310603:62;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталлары – 16:50:310604, 16:50:310603, 16:50:000000, 16:00:000000;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Мәскәү районы;
- билгеләү максаты: 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2 пункт нигезендә «Линия корылмасын – Түбән Кама – Казан участогындагы «Этилен үткәргечләр идарәсе» милек комплексын реконструкцияләү. ЭП-600 дән өстәмә күләмнәрне исәпкә алып, этиленны транспортлау өчен объектлар модернизацияләү» проекты буенча корылма төзүне, реконструкцияләүне тәэмин итү өчен кирәкле капиталь булмаган биналар, корылмалар (коймаларны, көнкүреш хезмәте күрсәтү урыннарын, түбәле корылмаларны да кертеп) төзү һәм төзелеш техникасын урнаштыру өчен;
- билгеләү вакыты: 24 ай;

1.2. гариза бирүче: «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2 пункт, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, проект: «Линия корылмасын – Түбән Кама – Казан участогындагы «Этилен үткәргечләр идарәсе» милек комплексын реконструкцияләү. ЭП-600 дән өстәмә күләмнәрне исәпкә алып, этиленны транспортлау өчен объектлар модернизацияләү».

2. Сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт билгеләнмәгән.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2, 3 һәм 4 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарга 2 һәм 4 номерлы кушымталардан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Түбән Кама Нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яки агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яисә Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктлар белән каралган максатларда ачык

сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә;


7.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 18 мартындагы 914 номерлы «“Аккош күле” җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территориясе турында»гы карары белән расланган «Аккош күле» махсус саклана торган табигать территориясен саклау һәм аннан файдалану режимын үтәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 июнендәге
1704 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**





<table>
<tr><td colspan="2">Масштаб: 1:7000<br>Координаталар системасы: МСК-16</td></tr>
<tr><td colspan="2">Шартлы билгеләр:</td></tr>
<tr><td>1</td><td>Яңа ясалган характерлы нокта</td></tr>
<tr><td>(розовый прямоугольник)</td><td>Ачык сервитутлар (Проектлана торган)</td></tr>
<tr><td>(синий контур)</td><td>Җир кишәрлекләре</td></tr>
<tr><td>16:50:310604, 16:00:000000, 16:50:000000</td><td>кадастр кварталы</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| 16:50:310604:78, 16:50:310604:292, 16:50:310604:77, 16:50:310604:52, 16:50:310604:51, 16:50:310604:3, 16:50:310604:293, 16:50:310604:294, 16:00:000000:68393 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

______________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 10 июнендәге
1704 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




| Масштаб: 1:5000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:310604, 16:50:310603, 16:50:000000, 16:00:000000 | кадастр кварталы |
| 16:50:310604:3, 16:50:310603:401, 16:50:310603:62 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

_______________________